## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 ноябрь, 2024 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 нчы ноябрендә 18 сәг 00 минутта , 2024 елның 23 нчы ноябрендә 18 сәг 00 минутта, 2024 елның 28 нче ноябрендә 18 сәг 00 минутта, 2024 елның 29 нче ноябрендә 18 сәг 00 минутта, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән "2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Федоровский торак пункты территориясендә гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (торак пункт чикләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 366 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -188, бу 51 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 188 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Федоровский торак пункты территориясендә һәм

аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (торак пункт чикләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү?»

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

3. Әлеге карарны мәгъүлүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгъүлүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы — Ф.Ф.Зәйнуллин